| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА<br>Табарлинского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Тәбәрле авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.11.2025 Тәбәрле авылы № 2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы « Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тәбәрле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законның 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тәбәрле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 14 ноябрендә 11сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тәбәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, (I төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, иреклеләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан) башка), 2026 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган

акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Тәбәрле авылында урамнарны яктыртуны карап тоту, хезмәт килешүе буенча штаттан тыш электрикка түләү һәм урамнарны яктырту буенча башка чыгымнар);

- торак пункт территориясен төзекләндерү ( Тәбәрле авылында юлларны кардан чистарту, чүп үләннәрен чабу, МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (Тәбәрле авылындагы чишмә территориясен төзекләндерү өчен иске койманы һәм су алу камерасын яңарту өчен чыгым материаллары сатып алу);

- каты көнкүреш калдыкларын туплау өчен мәйданчыклар булдыру, контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Тәбәрле торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекне бетерү)»

“КИЛЕШӘМ” “КАРШЫ”

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Тәбәрле авылы, Ленин урамы, 8А нчы йорт, авыл мәдәният йорты адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлегенең башкарма комитетына җыенны оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Салимуллин

Совет Табарлинского сельского поселения
Тәбәрле авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002519
АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ